| | |
|---|---|
| ГЛАВА КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

18.09.2017 д. Канаш № 8

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Канаш авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Канаш авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләр буенча уртак инициативасын чыгарырга:

«2018 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегенең һәр кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән ризамы:

1. Канаш аылы Үзәк урамында 150 метр озынлыктагы җирле әһәмияттәге юллар төзелеше һәм Зеленая урамында 20 метр су үткәргеч торба урнаштыру белән вак ташлы өслекле керү юлын төзү.
2. Түбән Күл авылында Боевая урамы буенча вак таш өслекле 250 метр озынлыктагы юллар төзелеше
3. Йолдыз авылындагы Меминка елгасы аша күперне реконструкцияләү өчен төзелеш материалы сатып алу

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы:

Н.Н. Вальков